# ТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

## (IV чакырылыш)

## КАРАР

IV чакырылыш чираттан тыш утырышы

2020 елның 30 декабре № 27 Урыссу ш.т.п.

.

*Татарстан Республикасы Ютазы район Советының «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар планлы чорына Ютазы муниципаль районы бюджеты турында" 2019 елның 13 декабрендәге 52 номерлы карары белән расланган III чакырылыш XXX утырышы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында*

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль закон, "Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы, «Ютазы муниципаль районында бюджет процессы турында" Нигезләмәсе нигезендә, Ютазы район Советы

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

***1 статья***

Ютазы муниципаль районы Советының «2020 елга һәм 2021, 2022 еллар планлы чорына Ютазы муниципаль районы бюджеты турында» 2019 елның 13 декабрендәге 52 номерлы III чакырылыш XXX утырышы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1) 1 статьяда:

а) 1 пунктның 1 пунктчасында «567 193,4» санын «608 322,7» санына алмаштырырга;

б) 2 пунктның 1 пунктчасында «577 495,1» санын «637 073,2» санына алмаштырырга;

в) 3 пунктның 1 пунктчасында «10 301,7» санын «28 750,5» санына алмаштырырга;

**2 статья**

Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр Порталындагы рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

3 **статья**

Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

.

**4 статья**

Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны Ютазы район Советының бюджет, салымнар, инвестицияләр һәм эшкуарлык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы
Рәисе А.Ә. Шәфигуллин